| | |
|---|---|
| **ГЛАВА УЛЬЯНКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УЛЬЯНКОВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

9 ноябрь, 2023 ел Ульянково ав. № 2

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлегенең Корноухово авылында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлеге Уставының 22 маддәсе нигезендә карар бирәм:

1. 2023 елның 23 ноябренә 10 сәгать 00 минутка Корноухово авылы, Бутанина урамы, 44 нчы йорт адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлеге Корноухово торак пунктында үзара салым алып бару мәсьәләләре буенча гражданнар җыенның беренче этабын билгеләргә.
2. 2023 елның 24 ноябренә 18 сәгать 00 минутка Корноухово авылы, Бутанина урамы, 58 нче йорт адресы буенча урнашкан Корноухово авыл клубында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлеге Корноухово торак пунктында үзара салым алып бару мәсьәләләре буенча гражданнар җыенның икенче этабын билгеләргә.
3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлегенең Корноухово авылы территориясендә даими яшәүче һәм яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

- Материаллар сатып алып су башнясын ремонтлау һәм хезмәт күрсәтү;
- Материаллар сатып алып урам яктыртуны ремонтлау;

- Материаллар сатып алып һәйкәлне төзекләндерү һәм ремонтлау;
- Авыл җирлеге торак пункты территориясен тоту».

«РИЗА» «КАРШЫ»

4. Әлеге карарны Ульянково авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.
5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Кайбыч муниципаль районы**
**Ульянково авыл җирлеге башлыгы** **Ф.А. Сундурова**